❒ Ә сез беләсезме?

Рөстәм хәзрәт ШӘЙХЕВӘЛИ

НАЧАР УЙ, СЕР САКЛАУ

Аллаһы Тәгалә әйтә: "Ий, мөэминнәр, куп гөманнан саклагыз, чынлыкта кайбер гөманда гөнаһ бардыр" (49.1).

Безнең күп фетнәләребез, әшәкелекләребез гөманнан, бер-беребез турында начар уйдан, начар фикердән башлана. Без үзебез дә сизмәстән шулайдыр, болайдыр дип уйлыйбыз һәм хәтта башкаларга сөйләмәсәк тә гонаһка керәбез. Шайтан безнең күңелебезгә шик кертә һәм без вакытында шул шиктән туктый алмасак, ул тышка чыгарга мөмкин. Шуңа күрә пәйгамбәребез с.г.в. әйтә: "Гөманнан сакланыгыз, чынлыкта гөман кылу иң ялган нәрсә".

Гөманны, шикне иң ялган нәрсә дип пәйгамбәребез с.г.в. безне башкалар турында гайбәт сөйләүдән, кимчелекләрен эзләп дәрәҗәләрен төшерүдән тыеп, аларны гамәлләренә карап хөкем итәргә өнди. Мөселманга башкаларның күңелләренә керү тыела. Чөнки кешенең күңелендә ни барын бер Аллаһ кына белә. Кеше хәтта теле белән бер нәрсә сөйләп тә, күңеле белән башка нәрсәдә булырга мөмкин.

Фикердә һәм гамәлдә ялгышмас өчен без һәрнәрсәне пәйгамбәребезнең сөннәтләре, аның яшәеше белән чагыштырырга тиешбез. Ул безгә шәригатьне, яшәү рәвешен калдырган һәм безнең уй-фикерләребез дә мөмкин кадәр шушы шәригатькә якын булырга тиеш. Шәригатьтән ерагайган саен безнең ялгышларыбыз күбәя, гөнаһларыбыз арта. Абд ар-Раззактан риваять кылына: Абдуллах ибне Утба ибне Масгуд әйтте: "Мин Гомәр ибне әл-Хаттаб р.г.дән ишеттем: "Пәйгамбәребез с.г.в исән вакытта кешеләр турында килгән вәхийләргә карап хөкем итә идек, әмма вәхий килүдән туктады. Һәм хәзер без сезнең турыда безгә күренгән гамәлләрегезгә карап хөкем итәбез. Әгәр дә кемгә дә булса безгә яхшылык эшләсә, без аңарга ышанабыз һәм үзебезгә якынайтабыз, аның күңелен тикшермибез, чөнки ул аның өчен Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә каршында хисап бирәчәк. Кем дә булса безгә начарлык эшли икән, безнең аңарга ышанычыбыз бетә, һәм без, ул никадәр генә үзенең күңелендә бернинди начарлык тә юк дип әйтсә дә, без аңарга ышанмыйбыз".

Бүген дә, безнең арада да хөкем гамәлебезгә карап була. Күңелем әйбәт диген, матур сүзләрне күп сөйләгән кешегә беренче тапкыр гына ышанырга мөмкин. Шайтан барыбызның да кан тамырларыннан йөри. Бөтенебезне дә котырта, ысуллары гына төрлечә булырга мөмкин. Шуның өчен артык уй-фикерләргә, шайтан коткыларына ирек бирмәскә кирәк. Ә моның өчен күбрәк Коръән, намазлар укырга, үлем-җан бирүебез турында, кыямәт көнендә барыбызның да җавапка басачагыбыз, ахирәтебез хакында уйларга кирәк. Безнең һәр әгъзабыздан соралачак, һәр әгъзабыз җавап бирәчәк. Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә әйтә: "һәм дәлилең, белемең булмаган нәрсәгә иярмә, ягъни дәлилсез гамәл дә кылма, хөкем дә итмә, фәтвә дә бирмә! Аллаһ биргән колак, күз, күңел - боларның һәрберсеннән кыямәт көнне сорау булыр".

Без шушы тыюларга буйсынырга фәкать төпле белемгә генә нигезләнеп сөйләргә тиешбез. Онытмыйк: безнең авызыбыздан чыккан һәр сүзебезне язып бара торган сакчы фәрештәләребез бар. Әгәр безнең иманнарыбыз көчле булса, шайтан күңелебезгә төрле уйлар сала башлау белән, күңел күзебезгә шул фәрештәләр күренер, ахирәтебез искә төшәр.

Аллаһы Сөбханә вә Тәгалә әйтә: "Сүз сөйләнмәс, мәгәр сөйләнгән һәрбер сүзне көтеп утыручы фәрештә язар".

Безнең, ничә буын динсезлектә тәрбияләнүебез сәбәпледер, иманыбыз шулкадәр зәгыйфь, ахирәт турында сөйләвебез юк дәрәҗәсендә, бәлкем ышаныбыз да шулай уктыр, ни сөйләгәнебезне дә уйламыйбыз. Пәйгамбәребез с.г.в. әйтә: "Чынлыкта, кайвакыт кеше Аллаһы Тәгалә риза булырдай ниндидер сүз әйтә, һәм ул үзенең сүзләренең нинди дәрәҗәләргә ирешүе турында күз алдына да китерә алмый, шул сүз өчен Аллаһы Тәгалә аны Үзе белән очрашканга кадәр мәрхәмәтлелек күрсәтә торганнарның берсеннән язар һәм чынлыкта, кайвакыт кеше Аллаһы Тәгалә риза булмастай ниндидер сүз әйтә. Һәм ул үзенең сүзләренең никадәр түбәнлеккә ирешүен күз алдына да китерә алмый, шул сүзе өчен Аллаһы Тәгалә аны кыямәт көненә кадәр Үзенең ачуында булучыларның берсеннән язар".

Әгәр безнең белемебез күп, иманыбыз көчле булса, күп сөйләшмәс идек. Күбрәк ахирәтебезне кайгыртыр идек. Чөнки күп сөйләшү безне гөнаһка гына этәрә. Пәйгамбәребез с.г.в. әйтә: "Кешенең ялганчылардан булуы өчен һәрбер ишеткәнен сөйләп йөрүе җитә".

Күңелгә килгән уйны, фикерне тышка чыгармау, ишеткәнне башкаларга сөйләмәү бездән бер хозур сабырлык таләп итә. Сер саклый белүе шулай ук мөселманнарның бер яхшы сыйфатларыннан санала. Бүген ихлас күңелдән дин таратырга ниятләсәң, "син бигрәк беркатлы җүләр" - диләр. Ә бит Ислам динен җүләрләр күтәргән. Әбү Бәкер р.г. намазга баскач күңеле йомшарып намазын укый алмас дәрәҗәдә елый торган булган. Шушы юаш, кешегә борылып карарга, авыр сүз әйтергә курка торган кешегә пәйгамбәребез вафатыннан соң ил белән идарә итү, хәлифәлек вазыйфасы йөкләтелә. Шулай булуга карамастан, дөньяда Ислам дине таралу кимеми, бәлки арта гына. Чөнки ул берүзе генә беркатлылардан булмый. Котдус шәһәре (Иерусалим) мөселманнар кулына күчкәч, Гомәр р.г. Котдус шәһәренә килә: иске киемнән, дөясен җитәкләгән хәлдә җәяү, ә дөясендә аның хезмәтчесе утыра. Ул бит хәлифә була, Котдус шәһәрендәге христианнар, яһүдиләр бар да шаккаталар: патшаларның көязләнеп халык арасында йөрүен күрергә өйрәнгән халык өчен бу искиткеч вакыйга була. Бүген дә югарыда утыручы даирәләребез җәяү дә йөри, кибетләрдә чиратта да тора, әмма шул беренче мөселманнардан аермалы буларак фәкать сайлау алдыннан.

Без бүген мөселманнар турында, аларның сыйфатлары хакында намаз укуына, Коръән укый белә алуына карап кына фикер йөртәбез. Әлбәттә, болар безнең өстебезгә йөкләтелгән бурычлар. Без боларны үтәргә тиешбез. Шәһәребездә, җөмһүриятебездә беренче тапкыр 90-нчы елларда хәреф өйрәнә, намаз укырга өйрәнә башладык. Ничә дистә еллар, ничә буын динсезлектән соң бу зур вакыйга иде. Без дә беркатлы идек. Намаз укый белгән кешенең колы булырга риза идек. Әмма вакыт узды, белемебез артты, ни үкенеч, нәкъ менә шушы намаз уку, Коръән уку, ураза тоту һ.б. өстебезгә йөкләтелгән бурычлар бүгенге көндә мөселманнарның таркаулыгына сәбәп булып тора. Берәүнең намаз укыганын күрсәк, күзәтә башлыйбыз, безнеңчә укыймы, безнеңчә укыймыймы? Ә бит ул да намаз укый дип куанырга гына кирәк. Коръән укыса да "мәкаме кемнеке?" дибез. Ә бит бөтен кешенең дә тавышы да матур, көе дә матур булмаска мөмкин. Иң әһәмиятлесе - ул намаз, Коръән укый. Хәтта нәфел уразасы тотуны да бидгать эшләүче дип әйтүчеләр бар.

Беребез намаз укыса, аны башкаларыбыз тикшермәскә иде. Пәйгамбәребез с.г.в. әйтә: "Әгәр дә өчәү булсагыз, башка кешеләр белән кушылганчыга кадәр икегез өченчегез янында пышылдашмасын, чөнки бу аның кәефен бозар".

Имам Мәликтән риваять кылына, Абдуллаһ бине Динар әйтте: "Бервакыт, мин ибне Гомәр белән Халид ибне Укбаның өендә булдым. Аның өе базардан ерак түгел иде. Шунда бер кеше килде һәм аның белән бергә-бер калып икесе генә сөйләшергә теләде. Ибн Гомәр тагын бер кешене чакырды, соңыннан миңа һәм шул чакырылган кешегә: "Бераз читкәрәк китегез әле, чөнки мин пәйгамбәребез с.г.в.нең, ягъни "сезнең икегез өченчегез янында пышылдашмасын" дип әйткәнен ишеттем".

Адәм баласы ашыгучан булып яратылган, шуңа күрәдер белгән, ишеткән әйберне тизрәк башкаларга сөйләр! Аз гына сабыр итсәк, бәлки сөйләүнең кирәгедә калмас. Әйткәнемчә, сер саклау мөселманның яхшы сыйфатларыннан санала.

Пәйгамбәребез с.г.в. Ислам дине иңә башлаганда бөтен халык җәһилияттә була. Гарәп халкы арасында эчү, зина, урлашу һ.б. тискәре сыйфатлар чәчәк ата. Әмма ислам динен кабул итү белән бу халык үткәндәге әшәкелекләрен оныта, бер-берсенең кимчелеген сөйләү генә түгел, хәтта бер нәрсә үзенә кагылмаса аны да башкаларга сөйләми.

Имам әл-Бухаридан риваять кылына: Гомәр р.г.нең кызы тол кала. Абдулла ибне Гомәр сөйли: "Гомәр әйтте: "Мин Госман ибне Аффан белән очраштым һәм аңарга: "Әгәр теләсәң, мин сиңа Хафса бинт Гомәрне бирәм:, - дип аңа хатынлыкка кызым Хафсаны тәкъдим иттем. Ул "Мин моның турында уйлап карармын", - диде. Һәм мин берничә көн көттем, ә шуннан соң ул мине очратты һәм: "Мин хәзер өйләнмәскә уйладым", диде. Бераз вакыт узгач мин Әбү Бәкер әс-Сиддик р.г.не очраттым һәм аңа: "Әгәр теләсәң, мин Хафса бинт Гомәрне сиңа кияүгә бирәм", - дидем, - дидем. Әмма Әбү Бәкер р.г. эндәшмәде, гомумән, ул миңа җавап итеп бер сүз әйтмәде. Минем аңа Госманга караганда да ныграк ачуым килде. Берничә көннән соң Пәйгамбәребез с.г.в. Хафсаны үзенә хатынлыкка сорады һәм мин аңа аны бирдем. Шуннан соң миңа Әбү Бәкер р.г. очрады һәм әйтте: "Син, бәлкем, миңа ачулангансыңдыр. Син миңа Хафсаны хатынлыкка тәкъдим иттең, ә мин бернинди дә җавап бирмәдем". Мин әйттем: "Әйе, - дип. Шунда ул: "Мин пәйгамбәребез с.г.в.нең Хафса турында әйткәнен ишеткән идем. Сиңа җавап бирергә шушы сәбәп комачаулады. Мин берничек тә пәйгамбәребез с.г.в.нең серен сөйли алмадым. Әгәр дә пәйгамбәребез с.г.в. аннан баш тарткан булса, мин аны һичшиксез үземә хатынлыкка алыр идем", - диде.

Пәйгамбәребез с.г.в. беркемгә дә кычкырып эндәшмәгән, боермаган. Ул үзенең әйткәннәрен, кешеләргә җиткергәннәрен җитә дип уйлаган, һәм аның әйткәнен бөтен кеше җиренә җиткереп эшләргә тырышкан. Коръәннән аять иңгән, ул аятьне үтәргә ашыкканнар: һәркем үзе белгәнчә. Берсе-берсеннән көлмәгән, берсе-берсен кимсетмәгән. Мин дөрес дип башкаларны да өйрәтеп йөрмәгән. Югыйсә аларның гыйлеме, ихласлыгы безнекеннән күпкә югарырак булгандыр. Ә бүген һәрберебез галим, һәм ни өчендер мәчеткә килгән кешене надан дип санап, аны үзебез уйлаган туры юлга кертергә ашыгабыз. Урамдагы, шәһәрдәге динсез халыкны дингә өндәү турында уйлап та карамыйбыз.

Мәчет вахабий эзле торган да, суфи эзле торган да урын булмаска иде. Мәчетләребез төрле уй-фикердә булуга карамастан, безне берләштерә, бергә намаз укый, бер кыйблага юнәле торган урыныбыз булса иде.

Өфөлә намаҙ ваҡыты

Сәфәр 2014 миләди йыл
1436 һижри йыл.

Сәфәр	Аҙна көндәре	Ноябрь, декабрь	Иртәнге намаҙ	Ҡояш сығыа	Өйлә нам.	Икен. нам.	Аҡшам.	Йәстү намаҙы
1	Йәкшәмбе	23	7.34	9.04	13.30	15.30	17.00	18.30
2	Дүшәмбе	24	7.35	9.05	13.30	15.29	16.59	18.29
3	Шишәмбе	25	7.37	9.07	13.30	15.28	16.58	18.28
4	Шаршамбы	26	7.39	9.09	13.30	15.27	16.57	18.27
5	Кесе йома	27	7.41	9.11	13.30	15.25	16.55	18.25
6	Йома	28	7.43	9.13	13.30	15.24	16.54	18.24
7	Шәмбе	29	7.44	9.14	13.30	15.23	16.53	18.23
8	Йәкшәмбе	30	7.46	9.16	13.30	15.23	16.53	18.23
9	Дүшәмбе	1	7.47	9.17	13.30	15.22	16.52	18.22
10	Шишәмбе	2	7.49	9.19	13.30	15.21	16.51	18.21
11	Шаршамбы	3	7.51	9.21	13.30	15.20	16.50	18.20
12	Кесе йома	4	7.52	9.22	13.30	15.19	16.49	18.19
13	Йома	5	7.53	9.23	13.30	15.19	16.49	18.19
14	Шәмбе	6	7.55	9.25	13.30	15.18	16.48	18.18
15	Йәкшәмбе	7	7.56	9.26	13.30	15.18	16.48	18.18
16	Дүшәмбе	8	7.58	9.28	13.30	15.17	16.47	18.17
17	Шишәмбе	9	7.59	9.29	13.30	15.17	16.47	18.17
18	Шаршамбы	10	8.00	9.30	13.30	15.17	16.47	18.17
19	Кесе йома	11	8.01	9.31	13.30	15.17	16.46	18.17
20	Йома	12	8.02	9.32	13.30	15.16	16.46	18.16
21	Шәмбе	13	8.03	9.33	13.30	15.16	16.46	18.16
22	Йәкшәмбе	14	8.04	9.34	13.30	15.16	16.46	18.16
23	Дүшәмбе	15	8.05	9.35	13.30	15.16	16.46	18.16
24	Шишәмбе	16	8.06	9.36	13.30	15.16	16.46	18.16
25	Шаршамбы	17	8.07	9.37	13.30	15.16	16.46	18.16
26	Кесе йома	18	8.08	9.38	13.30	15.17	16.47	18.17
27	Йома	19	8.09	9.39	13.30	15.17	16.47	18.17
28	Шәмбе	20	8.09	9.39	13.30	15.17	16.47	18.17
29	Йәкшәмбе	21	8.10	9.40	13.30	15.18	16.48	18.17
30	Дүшәмбе	22	8.10	9.40	13.30	15.18	16.48	18.18